ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЯНГА - САЛСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 18, с. Янга-Сала,
Арский муниципальный район, 422011

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢАСАЛА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Үзәк урам, 18 йорт, Яңасала авылы,
Арча муниципаль районы, 422011

Тел. (84366) 57-2-10, факс (84366) 57-2-10. E-mail: Yns.Ars@tatar.ru www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«23» декабрь 2025 ел** **№ 31**

**Пиротехник эшләнмәләрен файдалану өчен, рөхсәт ителгән урыннарны билгеләү турында**

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясы һәм «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XXII номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясы нигезендә Яңа ел бәйрәм чаралары чорында гражданнарның, физик һәм юридик затларның, дәүләт һәм муниципаль мөлкәтнең тормыш һәм сәламәтлек куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим урнаштыру турында» 22.12.2025 ел, № 1121 карары белән, Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы тәкъдимнәрен исәпкә алып, Яңасала авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Биеклеге 50 метрдан артыграк булган салютлар һәм фейерверклар үткәргәндә, шулай ук салютлар һәм фейерверклар биеклегенә бәйсез рәвештә җир яисә су өслегенә һава юллары полосаларын проекцияләү чикләрендә һава пространствосыннан файдалану Россия Федерациясенең Һава хәрәкәтен оештыруның бердәм системасы оператив органы (алга таба - вәкаләтле орган) рөхсәте белән гамәлгә ашырыла.

Фейерверк уздыру өчен вәкаләтле органнан рөхсәт алырга кирәк. Язма рөхсәттән башка муниципаль берәмлек территориясендә фейерверк уздыру тыела.

2. Пиротехник әйберләрдән файдалану өчен рөхсәт ителгән урын итеп түбәндәгеләрне билгеләргә:
- Яңасала авылында, елга аша чыккан күпердә.
- Каенсар авылына керү юлындагы плотинада.

3. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында һәм Яңасала авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: Яңасала авылы, Үзәк урам, 18 йорт; Каенсар авылы, Урта урам, 25 йорт.

4. Әлеге карарны куллануны контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Яңасала авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе

А.И.Сафин